ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

08 ноябрь, 2018 ел № 27/16

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә шәһәр төзелеше мәсьәләләре буенча иҗтимагый фикер алышу һәм җәмәгать тыңлауларын оештыру һәм үткәрү Тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5.1 маддәсе, 2003 елның 06 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ санлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә шәһәр төзелеше мәсьәләләре буенча иҗтимагый фикер алышу һәм җәмәгать тыңлауларын оештыру һәм үткәрү Тәртибен (алга таба – Тәртип) кушымтага нигезләнеп расларга.

2. Гамәлдән чыккан дип танырга:

1) Шәһәр Советының 2006 елның 10 февралендәге «Яр Чаллы шәһәре генераль планы проекты буенча гавами тыңлаулар хакында» 8/26 санлы Карарын, «Челнинские известия» газетасының 2006 ел, 01 марттагы 35-36 нчы саннарында басылган;

2) Шәһәр Советының 2006 елның 10 февралендәге «Яр Чаллы шәһәрендә җир кишәрлеген яки капиталь төзелеш объектын шартлы рәвештә рөхсәт ителгән файдалануга рөхсәт бирү һәм рөхсәт ителгән төзелешнең чик параметрларыннан кире кагуга, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүгә рөхсәт бирү мәсьәләлре буенча гавами тыңлаулар хакында» 8/27 санлы Карарын, «Челнинские известия» газетасының 2006 ел, 11

марттагы 42-44 нче саннарында басылган;

3) Шәһәр Советының 2006 елның 12 маендагы «Яр Чаллы шәһәре территориясен межалау, планлаштыру проектлары буенча гавами тыңлаулар хакында»12/4 санлы Карарын, «Челнинские известия» газетасының 2006 ел, 05 майдагы 93-94 нче саннарында басылган;

4) Шәһәр Советының 2006 елның 12 маендагы «Яр Чаллы шәһәрендә төзелеш һәм җирдән файдалану тәртибе буенча гавами тыңлаулар үткәрү тәртибе турында» 12/5 санлы Карарын, «Челнинские известия» газетасының 2006 ел, 05 майдагы 93-94 нче саннарында басылган;

5) Шәһәр Советының 2014 елның 16 октябрендәге «Шәһәр Советының «Яр Чаллы шәһәренең Генераль планына үзгәрешләр кертү турында» карар проекты буенча гавами тыңлаулар хакында» 33/15 санлы Карарының 3 нче пунктын;

6) Шәһәр Советының 2015 елның 17 июнендәге «Шәһәр Советының 2006 елның 10 февралендәге 8/26 санлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәренең Генераль планы проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрү тәртибе турында Нигезнамәгә үзгәрешләр кертү хакында» 40/10 санлы Карарын, «Челнинские известия» газетасының 2015 ел, 24 июньдәге 45 нче санында, «Шәһри Чаллы» газетасының 2015 ел, 24 июньдәге 45 нче санында басылган;

7) ) Шәһәр Советының 2015 елның 17 июнендәге «Шәһәр Советының 2006 елның 10 февралендәге 8/27 санлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәрендә җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан файдалануның шартлы рәвештә рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү һәм рөхсәт ителгән төзелеш эшләренең, капиталь төзелеш объектларын яңартып төзүнең иң чик параметрларыннан читкә китүгә рөхсәт бирү хакында сораулар буенча гавами тыңлаулар турында Нигезнамәгә үзгәрешләр кертү хакында» 40/11 санлы Карарын, «Челнинские известия» газетасының 2015 ел, 24 июньдәге 45 нче санында, «Шәһри Чаллы» газетасының 2015 ел, 24 июньдәге 45 нче санында басылган;

8) Шәһәр Советының 2015 елның 17 июнендәге «Шәһәр Советының 2006 елның 12 маендагы 12/4 санлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәренең территориясен планлаштыру проекты, межалау проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрү тәртибе турында Нигезнамәгә үзгәрешләр кертү хакында» 40/12 санлы Карарын, «Челнинские известия» газетасының 2015 ел, 24 июньдәге 45 нче санында, «Шәһри Чаллы» газетасының 2015 ел, 24 июньдәге 45 нче санында басылган;

9) Шәһәр Советының 2015 елның 17 июнендәге «Шәһәр Советының 2006 елның 12 маендагы 12/5 санлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрү тәртибе турында Нигезнамәгә үзгәрешләр кертү хакында» 40/13

санлы Карарын, «Челнинские известия» газетасының 2017 ел, 01 июльдәге 47 нче санында, «Шәһри Чаллы» газетасының 2015 ел, 24 июньдәге 45 нче санында басылган;

10) Шәһәр Советының 2015 елның 28 декабрендәге «Шәһәр Советының «Яр Чаллы шәһәренең Генераль планына үзгәрешләр кертү турында» карар проекты буенча гавами тыңлаулар хакында» 5/6 санлы Карарының 4 пунктын, «Шәһри Чаллы» газетасының 2016 ел, 21 гыйнварындагы 4 нче санында басылган.

3. Әлеге Карар үтәлешен тикшереп торуны Шәһәр Советының шәһәр төзелеше, шәһәр инфраструктурасын һәм торак-коммуналь хуҗалыкны үстерү мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев